ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әтнә муниципаль районы
Олы Мәңгәр авыл жирлеге Советы

422756, ТР Әтнә муниципаль районы,
Олы Мәңгәр авылы, Совет урамы, 8
тел. 34-6-25

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Большеменгерского сельского поселения
Атнинского муниципального района

422756, РТ, Атнинский муниципальный район,
село Большой Менгер, улица Советская, 8
тел. 34-6-25

# КАРАР

“29” август 2022 ел № 56

**«Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Мәңгәр авыл җирлегендә иҗтимагый тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында”гы 2018 елның 15 декабрендәге 84 номерлы карарга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында. (14.05.2021 ел карары редакциясендә)**

2021 елның 11 июнендәге 191-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы Федераль закон нигезендә, 2022 елның 29 июлендәге 02-08-02/Прдп239-22 номерлы Әтнә районы прокуратурасы протесты буенча фикер алышканнан соң, Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советы карар итте:

1. 2018 елның 15 декабрендәге 84 номерлы карары белән расланган (14.05.2021 ел карары редакциясендә) Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Мәңгәр авыл җирлегендә иҗтимагый тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә 1 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы: Ф.К.Тахавиев

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советының 2022 елнын 29 августындагы 56 нче номерлы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Мәңгәр авыл җирлегендә иҗтимагый тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (14.05.2021 елгы карар редакциясендә)**

Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советының 2018 елның 15 декабрендәге 84 номерлы карарына (14.05.2021 ел карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

7 статьяның 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

Иҗтимагый сөйләшүләрдә яки җәмәгать тыңлауларында катнашучылар мондый проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

1) рәсми сайт яки мәгълүмат системалары аша (җәмәгать фикер алышулары булган очракта);

2) иҗтимагый тыңлауларда катнашучыларның җыелышын яисә җыелышларын уздыру барышында язма яисә телдән (иҗтимагый тыңлаулар үткәрелгән очракта);

3) иҗтимагый фикер алышулар яисә җәмәгать тыңлаулар оештыручы адресына язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә.